**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЕШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423761, Аешавылы, Ленин ур., 34б йорт.

**СОВЕТ АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423761, село Аишево, ул. Ленина, дом 34б.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“10”НОЯБРЬ 2020 ЕЛ №2

Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегендә торак пунктында халык җыены үткәрү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Аеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Аеш авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 нчы елның 20 нче ноябрь көненә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда үзара салым түләүләрнең бер тапкыр - 500(биш йөз) сум күләмендә кертелүенә, 18 яшькә җиткән һәр гражданнан аларның яшәү урыны, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашуларына бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала,аларның саны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан артмаса, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:
1.Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
2.Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:
- зират территориясендә агач кисү;
зират коймасын төзекләндерү;
3.Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (грейдлау, кардан чистарту)
- юлларны формалаштыру һәм тигезләү, ПГС һәм вак таш салу, Ленин ур., Татарстан ур.;
4.Һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү;
5.Урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Аеш авылы, Ленин урамы, 34б йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Аеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Аеш авыл җирлеге башлыгы Д.Р.Ахатов